ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТЕЛӘКӘЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423749, Иске Теләкәй авылы,
Үзәк ур.,87 нче йорт.
Тел/факс 3-44-59

ТЛЯКЕЕВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423749, село Старое Тлякеево,
ул.Центральная,дом 87.
Тел/факс 3-44-59
Эл.адрес: telak-akt@yandex.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

От 24 октября 2024 г. № 12

«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Теләкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибе турында» Актаныш муниципаль районы Теләкәй авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 28 октябрендәге 20 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 маендагы 393 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 10 октябрендәге 1360 номерлы карары, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Теләкәй авыл җирлеге Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Теләкәй авыл җирлеге башкарма комитеты
**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Теләкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Теләкәй авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 28 октябрендәге 20 номерлы карарына (17.07.2020 елдан 13 номерлы, 07.10.2024 елдан 10 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1 **1 бүлегенең 5 пунктында**:
а) **3 пунктчада** "хисаплылыктан өземтә" сүзләрен "белешмә" сүзенә алмаштырырга.;»

б) **4 пунктчада** "Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160_1 статьясы нигезендә бюджетка түләүләр, алар буенча пенялар һәм штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү буенча бюджет керемнәре администраторы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Регламентында каралган"сүзләрен өстәргә.;

в) **5 пунктчада** җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"амнистия турында акт яисә штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгәннәргә карата ярлыкау акты яисә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычны, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә, түләтү мөмкинлеген югалта торган суд акты;";

түбәндәге эчтәлекле **абзац өстәргә**:

"гражданның судтан тыш банкротлыгы процедурасын тәмамлау турында банкротлык турында белешмәләрнең бердәм федераль реестрыннан белешмәләр булган документ.".;

2. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Т.Гайнетдинов